**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2024елның 20 мае** **38-РС номер**

**КАРАР**

**«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Лаеш муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясы нигезендә, шулай ук Муниципаль берәмлекләр составына керүче «Олы Кабан авыл җирлеге», «Хәерби авыл җирлеге», «Столбище авыл җирлеге», «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелгән торак пунктлар халкының ризалыгын исәпкә алып Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лаеш муниципаль районы «муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын һәм аңа материалларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы проектын караганда Лаеш муниципаль районы Советы вәкиле итеп Лаеш муниципаль районы башлыгы И.Ф. Зариповны билгеләргә.

3. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)..

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль районСоветы рәисе** **И.Ф. Зарипов**